# Икмәктән зур нәрә Юк

*(Тапктырар һә зирәкләр кичәсе)*



**Максат.** Игенче хезмәтенә, икмәккә тәрбиялөү.
**Материал.** Плакатлар “Икмөк- ил тоткасы”, “Икмөк – кояш һөм җи баласы”, “Иген иккөн, морадына җиткөн.”
Алдан өзерлек. Балалар белөн икмөккө багышланган шигырьлөр, җырлар өйрәнү.

**Тәрбияче.** Балалар, бүгенте тапкырлар һүм зирәкләер кичәсенең нәерсә турында барачагын табышмактан белегез әле:
Үзе түгәрәк,
Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк,
Әчкелтем дә төчкелтем,
Бар нәрсәдән кадерлерәк.

**Балалар.** Ипи, икмәк.
**Тәрбияче.** Бик дөрес. Икмәк – бөек сүз ул, балаар, аны ашларның солтаны, тормышның падишаһы дип атыйлар. Күперен пешкән икмәк исеннәен дә тәмлерәк хуш ис дөнҗяда юктыр. Аны ашап туймыйсың, ничек беткәнен дә сизми касалың. Нәкъ менә Ш. Галиев шигырендәгечә:

**Бала.** Түм-түгәрәк күмәч алып
Кайтып киләм кибеттәен.
Шулкадәрле хуш исле һәм
Тәмле икән нилектән?

Шундый җылы, шундый йомшак,
Әзләп-әзләп чеметәм.
Әзләп-әзләп чеметәм дә
Шактый гына киметәм.

Тукта әле, нишләп әле
Беләгкмне чеметзм?
Сизми дә калганмын икән –
Куенда күмәч беткән...

**Тәрбияче.** Балалар, кибеткәен каян килгән соң күмәч? (Балалар җават бирәләр). Икмәк үстерү өчен күп хезмәт куела. Бүгенте тапкырлар һәм зирәкләр кичәсендә сез икмәк турындагы белемнәрегензне күрсәтерсез.
Яле, кемнеө шәп игенче
Буласы килә икән?
Бездә бүген “Игенчеләр”,
“Сабанчылар” бармы икән?

**1 нче** “Сабанчылар” командасы.
Сабанчылар булмаса,
Ипине кем үстерер?
“Сабанчылар” командасы. “Сабанчылар командасыннан
“Игенчеләр” командасына
Ялкынлы кайнар сәлам.
“Игенчеләр” командасына. “Игенчеләр” командасыннан
“Сабанчылар командасына
Шулай ук сәлам.

**Тәрбияче.** Балалар, икмәк турында һәр команда иң җылы сүзләрне әйтсен әле.

**1 команда.** Яшәү чыганагы – кояш нурын,
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.

**2 команда.** Икмәк – игенчененең җан җылысы,
Җир-анага кадер хөрмәте.
Яшәү тамыры ул һәр йөрәкинеө
Шуңа кадерлибез икмәкне. (Энҗе Мөэминова)

**Тәрбияче.** Ипекәй турында бик матур сүзләр әйттегез, булдырдыгыз. Игенчелек – бик борынгы һөнәр. Җиргә тәүге бөртекләрне чәчәр алдыннан бабаларыбыз кырга чистарынып чыкканнар, аны иң изге эш дип санаганнар. Хәзер һәр команда элек ничек техникасыз чәчү чәчен , ашлык үстерүләрен хәрәкәтләр белән күрсәтсен әле. (һәр команда җир сөрү, чәчү, уру, сугу, җилгәрү, тегермәндә он тарту хәрәтләрен башкара.)

**Тәрбияче.** Ә хәзерге вакытта җир эшен ничек башкаралар?



**1 команда.** Тракторын тырылдатып,
Трауторчы килеп җитте,
Җирне сөреп тә китте,
Менә ничек булышты,
Трактор – шәп булышчы!

**Тәрбияче.** Ә ничек чәчәләр, кул беләнме?

**2 команда.** Трактор артында чәчкеч
Шундый да кызу йөрде,
Орлыкларны тигез итеп
Шундук чәчеп тә бирде.
Менә ничек булышты,
Чәчкеч дигән булышчы!

**Тәрбияче.** Игеннәрне чәчкәч нишләрә кирәк?

**1 команда.** Самолет килеп җитте,
Гүлдәп очып үтте,
Җирне ашлап та китте.
Менә ничек булышты,
Самолет- шәп булышчы!

**Тәрбияче.** Ашлыкка тагын нәрсә кирәк, балалар?

**2 команда.** Йомшак җилләр игеннәрне
Иркәләде, назлады...
Нурлар йотты, дым эчте...
Иген өлгереӊ җитте.

**Тәрбияче.** Игеннеәр өлгергәч, нәрсә белән уралар соӊ аны хәзерге вакытта?

**1 команда.** Ә хәзер кирәк кырга
Комбайн чыгарырга.
Комбайны шәп икән,
Үзе ура, үзе суга,
Үзе җилгәрә икән.
Бик тырышып булышты,
Комбайн – шәп булышчы!

**Тәрбияче.** Балалар, мул уңыш алу өчен, шулай итеп, нәрсәләр булыша соң безгә?

**2 команда.** Машиналар ярдәм итте,
Әнә нинди күп алар.
Трактолар, торалар. (Р. Вәлиева)
(Җыр “Чайкала иген курлары”. Исмай Шәмсетдинов көе, Галимҗан Латыйп сүз.)

**Тәрбияче.** Тәмле күмәчләр булып, өстәлебезгә, әнә никадәр һөнәр ияләре кулыннан уза икән икмәк.
Гәрәбәдәй булып үсте иген,
Түгелгән тир бушка китмәде.
Игенченең батыр хезмәте бу –
Күпереп пешкән арыш икмәге.
Ә хәзер командалар җыеп алынган уңыштан нинди камыр ашлары пешерергә мөмкин булуын әйтсеннәр әле.
(Командалар татар халык ашларын санйлар: гөбәдия, дәвәш, чәк-чәк, кош теле, өчпочмак, пәрәмәч, бәлеш, бөккән, коймак, кыстыбый, күмәч һ.б.)

**Тәрбияче.** Әйдәгез, балалар, “Коймаклар” җырлы-уенын уйнап алабыз. (Уен уйнала. “Ак калач” уенының бер варианты. “Әткәм-әнкәмнең теле”. Закирова К. В.)

**Тәрбияче.** Балалар, иң кадерле ризык нәрсә соң ул?

**Бала.** Иркен кырларның исен,
Кояшның тәмен, төсен,
Җир әнкәбезнең көчен,
Үзенә җыйган өчен,
Дөнҗяның тиңсез ашы,
Табыннарның кояшы-
Ипекәй диләр аны,
Улдыр-Ашлар солтаны!( Р. Вәлиева.)
(Ш. Галиев сүзләремә язылган “Кунаклар” дигән җыр башкарыла, С. Сабирова көе.)

**Тәрбияче.** Балалар, Икмәк турында мәкаләрне искә төшерик әле. “Сабанчы” командасы мәкалҗнең башын, “Игенче” командасы ахырын әйтә.
-Икмәк – (җир кояш баласы).
-Ипекәйне кадерсезләмә, (үзең кадерсезлеккә төшәрсен).
-Икмәкнең валчыгы да бездән олы, (коеп ашама).
-Сабанда тирләмәсәң, (ындырда чирләрең).
-Авыр эш (калач ашата).
**Ипекәйне.** Ә хәзер “Игенче” командасы мәкалҗнең башын, “Сабанчы” командасы ахырын әйтә.
-Икмәкнең әрәм-шәрәм итү – (зур гөнаһ).
-Ипи-тоз – (якты йөз).
-Кар күп булса – (иген уңар).
-Сабанда сайрашмасаң (ындырда ыңгырашырсың).
-Ипидән зур (нәрсә юк).

**Тәрбияче.** Ә хәзер командалар бер-берсенә табышмаклар әйтсеннәр.
“Сабанчы” командасы.

1. Диңгез түгел, дулкынлана. (Иген.)

2. Кара сарыкның тиресен
Әйләндереп капладылар. (Җирне сукалау.)
3. Үзе ура, үзе суга,
Үзе капчыкка сала.
Шаулап-гөрләп эшләгәндә,
Кыр матурланып кала. (Комбайн.)
4. Ду-ду ипет үкерә,
Басу иңләп йөгерә .
Бөтен кырда игенне
Урып-сугып бетерә. (Комбайн.)
“Игенче” командасы.
1. Ат түгел, кешнәми,
Иөз аттан ким эшләми.
Үзе йөри тыр да тыр,
Я, ул нәрсә, кем әйтер. (Трактор)
2. Болытсыз көнне яңгыр ява. (Он иләү)
3. Үзе суга, үзе җилгәрә,
Үзе төяп җибәрә.
Бик күп җыеп игенне,
Баета ул илемне. (Комбайн.)
4. Куәте бар, аңы юк.
Гәүдәсе бар, җаны юк. (Трактор).

**Тәрбияче.** Балалар, шагыйрьләребез икмәк, ипекәй турында бик күп шигырьләр иҗат иткәннәр, командаларны тыңлап карыйк әле.
“Сабанчы” командасы.
**Бала.** Һәркемгә ипи кирәк!
Һәм көн дә ипи кирәк!
**Бала.** Ипи космонавтка да,
Очучыга да кирәк.
**Бала.** Ипи яңа йолдызлар
Ачучыга да кирәк.
**Бала.** Ипи – эшләмичә тик
Ятучыга да кирәк.
**Бала.** Ипи, кибеттә ипи,
Сатучыга да кирәк.
“Игенче” командасы.
**Бала.** Ипи сезгә дә кирәк,
Ипи безгә дә кирәк, -
Һәммәбезгә дә кирәк!
**Бала.** Ипи эшләргә кирәк,
Юллар сузарга кирәк.
**Балда.** Ипи безгә дә кирәк:
Үсеп җитәргә тизрәк!
**Бала.** Шуңа да игенчене
Хөрмәт иәргә кирәк! (Роберт Миңнуллин)
**Тәрбияче.** Әйе, балалар, ипи һәркемгә дә кирәк, ансыз яшәп булмый. Ипи бик кыйммәтле ризык, аның һәр бөртеген тир агызып, эшләп табалар. Донҗяда аннан дакадерлерәк нәрсә юк. (Булмәгә “Ипекәй” керә, кулына сөлге белән ипи тоткан.)
**Ипекәй.** Туган җирнең кадере,
Назы булып үскәгә. Игәнче кулыннан
Гөлдәй тамып төшкәнгә,
Мин татлы, тәмпле булам,
Табында балкып торам.
Шуңа мине олылап,
Ипекәй дип атыйлар.
Ташламыйлар-атмыйлар,
Изге күреп саклыйлар.
Әрәм итмәгез мине
Һәм рәнҗетмәгез берүк... (Резеда Вәлиева)
Балалар, икмәне кадерләгез, миннән сезгә күпереп пешкән икмәк.
(Тәрбиячегә тапшыра.)
**Тәрбияче.** Рәхмәт, Ипекәй! Балалар, сез ниди үгет-нәсихәт беләсез әле?
**Командалар.** – Икмәкнең валчыгы да бездән олы.
- Сыныгыңны ашап бетер, бәхетеңне калдырасың бит.

- Икмәкне әрәм-шәрәм итмә.

**Тәрбияче.** Әти –әни, Ватан һәм дә икмәк!
Бу сүзләрдә тормыш мәгънәсе.
Бәхет, хезмәт, ирек, яшәү яме
Шул сүзләргә бәйле һәммәсе!

**Тәрбияче.** Тапкурлар һәм зирәклә без икмәкнең һәр кисәге, һер телеме изгебулуы турында сөйләштек. Без икмәкне кадерләсәк кенә рәхәт яши алачакбыз. Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез. (Йомгак ясала.)

**Источник:** Тәбигәтьнең сафлыгы – күңелнең пәкълеге. – Яр чәллы – 2004.